# Татар мультфильмнары ил киңлекләрен даулый.

Рәсәй милләтләре белән бай ил. Һәрберсенең үз йөзе, үз көнкүреше. Балаларга милли тәрбия бирүне кече яшьтән үк башларга кирәк. Сабыйларда туган телгә мәхәббәт уятуның визуаль ысулларын куллану аеруча үтемле. Балаларны шәхес итеп тәрбияләүдә мультфильмнарның роле гаять зур. Теләсә нинди милләтнең мәкальләрен, авыз иҗатын файдаланып мультфильмнар төшерергә мөмкин.

Ә менә анимация — шактый катлаулы сәнгать, аны эшләп чыгу өчен дә зур чыгымнар сорала. Анимация тасмасының бер минуты якынча 4 мең сумга төшкәнлеге мәгълүм. “Татармультфильм” еш кына Татарстан Министрлар кабинеты, Мәгариф һәм фән министрлыгының төрле грантларын ота килә.

“Татармультфильм” төшергән мультфильмнарны Интернет челтәре аша табарга мөмкин. Хәзергесе көндә зур уңышка ирешкән “Бала.рф” мультемидиа интерактив китапханәдән балалар да, өлкәннәр дә бик теләп файдалана. Айпад һәм айфоннар өчен “Tatar cartoon” кушымтасы эшләнгән. Әлеге кушымтада татар студиясе җитештергән барлык әсәрләр белән дә танышырга мөмкин. “Татармультфильм” дигән нәшрият тә оешкан. Өч телдә чыккан әкиятләр китабына кушып диск та бүләк ителә. Монда мультипликаторлар геройларын татар, урыс һәм инглиз телләрендә сөйләштерә. Бу – бик зәвыклы һәм һәркемгә дә тансык күчтәнәч. Оешма Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы белән дә тыгыз элемтәдә эшли.

Татар мультфильмнары балалар бакчаларына да таратылды. Ул мультфильмнарны балалар төркемнәрдә, аралашу (татар теле) эшчәнлекләре барышында, теләгән бала өйләренә алып кайтып, әти-әнисе белән дә карый ала. Эшчәнлек барышында башка милләт балалары да бу мультфильмнарны бик яраталар. Нәниләр мультфильм геройларына кушылып таныш сүзләрне кабатлыйлар, җырларын бергәләп җырлыйлар.

Татар мультфильмнары Европа киңлекләрен дә даулый. “Татармультфильм” оешмасының Абдулла Алиш әсәрләре нигезендә эшләнгән мультфильмнары Франциягә кадәр барып җитте.

Бакчаның татар теле тәрбиячесе

Вәлиева Миләүшә Мәзхәт кызы